КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инспекция үз компетенциясе кысаларында билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максат һәм бурычлар өстенлеген тәэмин итә.»;

3.2 пунктта:

уникенче абзацта «әйләнә-тирә табигый мохит өлкәсен контрольдә тоту буенча» сүзләрен «хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекне гамәлгә ашырганда төбәк

дәүләт экология күзәтчелеге, федераль дәүләт экология күзәтчелегенә караган объектларны куллану эшчәнлегеннән тыш» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

унсигезенче абзацта «Федераль теркәү хезмәтенең Баш идарәсе» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта:

«$13.19^2$ статьяның 1 өлешендә (күпфатирлы йортлар төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә),» сүзләреннән соң «$13.19^3$ статьяда (йорт төзүче, төзүченең вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә),» сүзләрен өстәргә;

«14.28 статьялар белән,» сүзләрен «14.28 статьның 1 – 5 өлешләре белән,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе структурасында «Экспертизалар, тикшерүләр һәм сынаулар үткәрүгә күзәтчелек итү буенча территориаль орган» сүзләрен «Тикшерүләр һәм сынаулар үткәрүгә күзәтчелек итү буенча территориаль орган» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин